# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәм салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында

**1 статья.** «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәм салым турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2439 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма бсмасы, 1999, №12; Республика Татарстан, 2001, 20 октябрь, №210-211) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәне кертергә:

1. 1 статьяның өченче пунктында:

беренче абзацта «бюджеттан тыш дәүләт фондларына түләүләр, шулай ук» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

8 пунктчада «керем салымын» сүзләрен «керемнәргә салымны» сүзләренә алыштырырга;

9 пунктчада: «керем салымын» сүзләрен «физик затларның керемнәренә салымны» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) бердәм социаль салымны».

2. 5 статьяда «20 процент күләмендә» сүзләрен «15 процент күләмендә» сүзләренә алыштырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән бер ай үткәч һәм эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләтелгән керемгә бердәм салым буенча чираттагы салым алу чорының беренче числосыннан иртә булмаган вакытта үз көченә керә.

Әлеге Законның гамәлдә булуы 2002 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш. Шәймиев

Казан шәһәре,
2002 елның 17 гыйнвары

№ I292